ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.05.2019 Олы Кайбыч авылы № 258

Кайбыч муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре исемлеген кертү тәртибен раслау, һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге һәм эффективлыгы күрсәткечләрен раслау турында

2003нче елның 6нчы октябрендә чыккан 131-ФЗномерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законы, 2008нче елның 26нчы декабрендә чыккан 294-ФЗ номерлы «Юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең дәүләт контроле (күзәтүе) һәм муниципаль контроль башкарганда хокукларын саклау турында» Федераль законы, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019елның 20апрелендәге 324 номерлы «О состоянии исполнительской дисциплины, выполнения исполнительными органами государственной власти Республики Татарстан Государственного задания на управление исполнительным органам государственной власти Республики Татарстан по индикаторам оценки качества жизни населения и эффективности их деятельности по итогам 2018 года» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР КЫЛА:

1. Кайбыч муниципаль районы территориясендә гамәлә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре исемлеген расларга (Кушымта №1).

2. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге һәм эффективлыгы күрсәткечләрен расларга (Кушымта №2).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнашкан “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары Э.Х. Заһидуллинага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров

Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2019нчы елның
«29»нчы маенда чыккан 258нче
номерлы карарына Кушымта №1

**Кайбыч муниципаль районы территориясендә гамәлә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре исемлеге**

1. Әлеге Тәртип муниципаль контроль төрләре исемлеген һәм «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан муниципаль контроль алып баруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеген билгели.

2. Муниципаль контроль төрләре исемлеген һәм «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан муниципаль контроль алып баруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеге системалаштырылган мәгълүматлар исемлеген күрсәтә:

а) муниципаль берәмлек җирле үзидарә органнары башкара торган муниципаль контроль төрләре турында;

б) муниципаль берәмлек территориясендә тиешле муниципаль контроль төрләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары атамалары турында;

в) Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, тиешле муниципаль контроль төрен көйләүче «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хокукый актлары реквизитлары турында.

3. Исемлекне формалаштыру һәм алып бару Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Исемлекне раслау, исемлектәге мәгълүматларга үзгәрешләр кертү, мәгълүматларны төшереп калдыру Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән рәсмиләштерелә.

5. Исемлектәге мәгълүматларга үзгәрешләр кертү, я булмаса мәгълүматларны төшереп калдыру нигезе булып «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарына эшчәнлекнең тиешле өлкәләрендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләре бирә торган хокукый нормаларны гамәлдән чыгару яки үзгәртү турында норматив хокукый акт кабул итү тора.

6. Исемлекне алып бару түбәндәге форма буенча гамәлгә ашырыла. “Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеге алып бару формасы.

| № п/п | «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төре атамасы | "Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле "Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге жирле үзидарә органы атамасы | Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары , тиешле муниципаль контроль төрен көйләүче «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге жирле үзидарә органнары муниципаль хокукый актлары реквизитлары |
|---|---|---|---|
| | Муниципаль җир контроле | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы җир һәм милек мөнәсәбәтләре Палатасы | Башкарма комитетның 2019елның 29мартындагы 151 номерлы « Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләрнең административ регламентын раслау турында" карары; Советның от 22 апрелендәге 2019елның 160 номерлы « Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә җирләрне куллану буенча муниципаль җир контроле турында Нигезләмәне раслау турында» карары |

Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2019нчы елның
«29»нчы маенда чыккан 258нче
номерлы карарына Кушымта №2

## Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге һәм эффективлыгы күрсәткечләре

| № п/п | Күрсәткечләр | Исәпләү методикасы | |
|---|---|---|---|
| 1 | Алдагы елга карата муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча чаралар саны , % | Еллык күрсәткеч | **V = A / B x 100 %**, монда<br>А- агымдагы елда муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча профилактик чаралар саны;<br><br>В- алдагыелда муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча профилактик чаралар саны. |
| 2 | Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан төзекләндерү кагыйдәләрен бозганда закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян салу факторларының кимүе, % | Еллык күрсәткеч | **V = (A / B- A1 / B1) x 100 %,** монда<br>А- узган елда муниципаль кагыйдәләрне бозган өчен административ штраф салу турында төзелгән беркетмәләр саны , (Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар турында Кодексының ст.3.6.);<br>А1- агымдагы елда муниципаль кагыйдәләрне бозган өчен административ штраф салу турында төзелгән беркетмәләр саны. (Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар турында Кодексының ст.3.6.); В- узган елда үздырылган планлы рейд караулары саны (систематик мониторинг), ;<br>В1- агымдагы елда үздырылган планлы рейд караулары саны<br>(систематик мониторинг), |
| 3 | Аларга карата административ регламент кабул ителгән муниципаль контроль төрләре өлеше, муниципаль райондагы контроль төрләренең гомуми санынан<br>, % | Еллык күрсәткеч | **V = A / B x 100 %,** монда<br>А- муниципаль контроль гамәлгә ашыруның кабул ителгән административ регламенты саны;<br>В- муниципаль контрольнең расланган төрләре |